УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.06.2026 г.Казань 01-05/94-пр

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясы, Татарстан Республикасы Президентының «Вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указлары нигезендә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба – Вазыйфалар исемлеге) (кушымтада бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең «Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2024 елның 13 маендагы 01-05/137-пр номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

Җитәкче А.Ш. Борһанов

Татарстан Республикасы Дәүләт
техник күзәтчелек идарәсенең
____________________ № _______
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең иң югары вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе башлыгы.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең төп вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе башлыгы урынбасары.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең районнардагы, шәһәрләрдәге бүлекләре җитәкчеләре;

оештыру-хокукый һәм кадрлар эше бүлеге җитәкчесе;

икътисадый анализ, эшчәнлекне тәэмин итү һәм дәүләт сатып алулары бүлеге җитәкчесе;

күзәтчелек һәм автоматлаштырылган рәвештә исәпкә алу бүлеге башлыгы;

аттракционнарга күзәтчелек һәм махсус юллардан йөри торган транспортка дәүләт контроле бүлеге башлыгы.

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «белгечләр» категориясе вазыйфалары:

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең районнардагы, шәһәрләрдәге бүлекләре консультантлары;

икътисадый анализ, эшчәнлекне тәэмин итү һәм дәүләт сатып алулары бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

аттракционнарга күзәтчелек һәм махсус юллардан йөри торган транспортка дәүләт контроле бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе.

5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

икътисадый анализ, эшчәнлекне тәэмин итү һәм дәүләт сатып алулары бүлегенең әйдәп баручы белгече;

күзәтчелек һәм автоматлаштырылган рәвештә исәпкә алу бүлегенең әйдәп баручы белгече;

оештыру-хокукый һәм кадрлар эше бүлегенең әйдәп баручы белгече –

коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат;

оештыру-хокукый һәм кадрлар эше бүлегенең әйдәп баручы белгече – эшчәнлекне хокукый тәэмин итүне гамәлгә ашыру өчен җаваплы зат;

әйдәп баручы киңәшче — мобилизация эше буенча белгеч.

6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең өлкән вазыйфалар төркемендәге «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

күзәтчелек һәм автоматлаштырылган рәвештә исәпкә алу бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;

икътисадый анализ, эшчәнлекне һәм дәүләт сатып алуларын тәэмин итү бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече.